РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2020 елның 21 мае

91-3 нче номерлы

2014 елның 24 ноябре 1-58 номерлы Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы карары белән расланган
«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең
коррупцион хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы
турындагы Нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарсатан Республикасы Законы, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, коррупциягә каршы тору турындагы законнарны тормышка ашыру максатыннан Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы турындагы Нигезләмә»гә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 1 бүлеге 1.3 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә расларга: «Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл
җирлеге башлыгы

И.И. Гәлиуллин